Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге составына керүче Беренче Май торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елның 16 ноябре

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлегенең Беренче Май торак пунктында граждannар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Ширәмәт авыл җирлеге Беренче Май торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 1600 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны чишмәне төзекләндерүгә (төзелеш материаллары сатып алуга, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләүгә) юнәлдерергә.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Ширәмәт авыл җирлеге җыенының 14.11.2020 нче елның 7нче номерлы карары нигезендә Первомайский торак пунктында, халыктан сууткәргеч һәм коелар төзүгә (материаллар сатып алуга, эшләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә) ике йөз кырык мең сум күләмендә җыелган үзара салым акчаларын Үзәк урамындагы юлга вак таш сатып алуга юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ширәмәт авыл җирлеге башлыгы

В.И. Никишин